РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

21.10.2020　　　　　　　　　　№ 1410-п

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының экологик
куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль
программасын раслау турында

Әйләнә-тирә мохитнең халык тормышы һәм сәламәтлеге сыйфатын яхшыртуның, ресурслардан нәтиҗәле һәм экологик яктан имин файдалануның, табигать комплексларының балансны үсешенең, аларның биологик төрлелеген саклауның кирәкле шарты буларак уңай торышын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының экологик куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Программаның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б. Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы　　　　　　　　　　М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 21 октябрендәге
1410-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының экологик куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының экологик куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләүче | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максатлары | Төп максатлар:<br>- Халыкның тотрыклы үсешенең һәм социаль-икътисадый яклангандлыгының кирәкле шарты буларак, рациональ һәм экологик яктан куркынычсыз ресурслардан файдалану<br>- Табигать комплексларының балансы үсеше, аларның биологик төрлелеген саклау<br>- Халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | Төп бурычлар:<br>• Гамәлдәге минераль-чимал комплексын саклап калу һәм үстерү, геологик мохитне имин файдалану<br>• Муниципаль район территориясендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту<br>• Муниципаль район территориясендә өске суларның сыйфатын яхшырту<br>• Туфракларны таралудан, җимерелүдән, пычратудан саклау, табигый комплексларның деградацияләнүен булдырмау, муниципаль район территориясендә туфракның уңдырышлылыгын күтәрү<br>• Муниципаль район территориясенең әйләнә-тирә мохитенә һәм санитар-эпидемиологик торышына калдыкларның тискәре йогынтысын киметү, булдырмый калу һәм туктату<br>• Муниципаль район территориясендә әйләнә-тирә мохит сыйфатын мониторинглау челтәрен үстерү<br>• Муниципаль район территориясендә әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу |

| | |
|---|---|
| | • Белем бирү учреждениеләрендә белем һәм тәрбия бирү функцияләрен ныгыту һәм үстерү, экологик тәрбия субъектлары составын киңәйтү, аларның тырышлыгын координацияләү, муниципаль район территориясендә гаилә һәм мәгариф учреждениеләренең үзара хезмәттәшлеген үстерү<br>• Муниципаль район халкының гражданлык үзаңы дәрәҗәсен күтәрү, аның әйләнә-тирә мохит сыйфаты турында хәбәрдар булуы. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2021 - 2025 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу<br>2.2021-2025 елларга Татарстан Республикасының Саба районында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә идарә |
| Программаны финанслау күләмнәре | 2021-2025 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 9 035,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2022 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2023 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2024 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2025 ел - 1 807,000 мең сум.<br>2021-2025 елларда Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслауның күләме 0,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 ел - 0,000 мең сум;<br>2022 ел - 0,000 мең сум;<br>2023 ел - 0,000 мең сум;<br>2024 ел - 0,000 мең сум;<br>2025 ел - 0,000 мең сум.<br>2021-2025 елларда Программаны Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның күләме 9 035,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2022 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2023 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2024 ел - 1 807,000 мең сум;<br>2025 ел - 1 807,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Саба муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы | Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне :<br>• пычранган агып төшүче суларның чагыштырмача |

| | |
|---|---|
| нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | агуын киметүне (тулаем региональ продукт берәмлегенә исәпләгәндә);<br>• атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бүленеп чыгуын киметүне (тулаем региональ продукт берәмлегенә исәпләгәндә) тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. |

## 1. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдә төп проблемаларны тасвирлау һәм аның үсеш фаразы

Соңгы вакытта, дәүләт дәрәҗәсендә дә, иҗтимагый аңда да, торган саен тизәя барган фәнни-техник прогресс дәрәҗәсендә цивилизациянең алга таба үсеше, шул ук вакытта табигатькә кертелә торган, еш кына кире кайтарып булмый торган үзгәрешләргә карамыйча, барыннан да элек, планетаның иң мөһим биотик өлеше буларак, кеше өчен коточкыч һәм куркыныч нәтиҗәләргә китерәчәген аңлау ныгый. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, хуҗалык һәм экологик бурычларны баланслы хәл итүне гамәлгә ашыручы озак вакытлы экология сәясәтенең фәнни нигезе булып Татарстан Республикасының табигатьтән нәтиҗәле файдалануга һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынтыны киметүгә юнәлдерелгән тотрыклы үсешкә күчү концепциясе тора.

Саба районында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану мәсьәләсе аеруча әһәмияткә ия. Район сәнәгатенең төп өлеше Байлар Сабасы бистәсенең Көньяк өлешендә тупланган, анда район халкының 25 % ка якыны яши. Табигатьне саклау проблемаларының шактый өлеше һәм предприятиеләрдә җитештерү күләмнәренең артуы экологик вәзгыятькә йогынты ясый. Районның авыл хуҗалыгы җитештерүе белән тәкъдим ителгән төп өлеше табигатькә антропоген басым сыйфатында азрак дучар. Соңгы елларда өлгереп җиткән экологик проблемалар спектры аларны хәл итү һәм Саба районы территориясенең табигый-тарихи (табигый) потенциалын саклау өчен кичектергесез һәм комплекслы якын килү таләп итә, чөнки аңа җәмгыятнең сәламәтлеге һәм байлыгы бәйле.

Саба районында әйләнә-тирә мохитнең торышы:

1. Атмосфера һавасының торышы.

Казан-Шәмәрдән автомагистрале атмосфера һавасын пычратуга зур өлеш кертә. Байлар Сабасы ш.т.б. һәм Шәмәрдән авылы урамнарын әйләнеп узу юллары төзелеше тәмамланды, алар транзит агымын авыл җирлекләре чикләреннән читкә чыгару хисабына автотранспорттан чыккан начар газларны киметергә мөмкинлек бирде.

2.Радиация-гигиена вәзгыяте.

Радиация-гигиена контроле нәтиҗәләре буенча Саба районында радиация торышының халәте канәгатьләнерлек булып кала бирә.

Халыкны нурландыруның әйдәп баручы факторлары булып табигый чыганаклар һәм медицина рентгенодиагностик процедуралары кала.

Территорияләрне бүлеп бирү, биналарны файдалануга кабул итү барышында радиация параметрлары буенча тикшерүләр саны артты. Эчә торган су һәм туфрак составында радионуклидлар булу-булмауга тикшерелгән. Барлык очракларда рөхсәт ителә торган дәрәҗәнең артуы ачыкланмаган.

3. Су ресурсларының торышы.

Саба районын су белән тәэмин итүнең төп чыганаклары - җир асты сулары.

Җир асты чыганакларыннан су, хуҗалык һәм эчү ихтыяҗлары һәм техник су үткәргечләре булмаган предприятиеләрнең житештерү ихтыяҗлары өчен файдаланыла.

Агынты суларны агызуның төп урыны- Саба елгасы. Бу сәнәгать предприятиеләренең, шәһәр чистарту корылмаларының һәм торак кварталларының Саба елгасы буенда урнашуы белән аңлатыла.

Саба районы халкын эчәргә яраклы су белән җир асты чыганакларыннан 24 су җыю җайланмасы (62 артезиан скважинасы) һәм 14 каптаж (14 чишмә) тәэмин итә. Хәзерге вакытта халыкның 99 %ы үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителештән файдалана.

Байлар Сабасы һәм Шәмәрдән авылында яшәүче халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү җир асты чыганакларыннан гына башкарыла. Хәзерге вакытта халыкның 100 %ы үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителештән файдалана.

Халыкның эчә торган ихтыяҗларына бирелә торган су гомуми катылык буенча “эчә торган су” ГОСТ 2874-82 таләпләренә һәрвакытта да җавап бирми, фторның түбән дәрәҗәсе күзәтелә.

Кече елгаларның төп пычрану чыганаклары булып сөт-товар фермалары, терлекләрнең җәйге лагерьлары тора. Фермаларда тирес саклау урыннары һәм чистарту корылмалары юк. Тирес турыдан-туры фермалар территориясендә яки алар янында төзелә. Аның бер өлеше су саклау зоналарында урнашкан кырларга ашлама сыйфатында чыгарыла.

Саба районы территориясендәге күлләр үзләренең урнашу урыннары буенча елгаларны аера торган,су баса торган һәм урман күлләренә карыйлар. Күлләрнең күбесендә авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен яраклы су бар, чөнки аларда үз-үзләрен чистарту процесслары бара.

4. Биологик ресурсларның торышы.

Төбәкнең үсемлекчелек тибы-урман-дала. Урманнар утрау характерында, җирләрнең күп өлеше сөрелгән. Районда Саба урманчылыгы урнашкан.

Саба районының фаунасы тайга, имәнлек һәм дала фаунасының кушылуы белән характерлана, анда төньяк урман төрләре күбрәк.

Тайгадагы хайван төрләреннән ак куян, кыр тычканы, аю, селәүсен, боҗыр, урман тавыгы, ябалак, кара тукран, тукран, чукыр, эрбет чыпчыгы, песнәк, борындык, поши һәм башкаларны очратырга мөмкин. Районның фаунасын төзүдә урман-дала һәм далалар вәкилләре зур роль уйный: соры көртлек , бытбылдык, ябалак, чуртан,тургай, солы чыпчыгы, көзән, сары йомран, әрлән.

5. Җитештерү һәм куллану калдыклары.

Саба районы производстволарында югары дәрәҗәдә агулы булган калдыклар барлыкка килми. Калдыкларның иң агулы төре булып терекөмеш белән эшкәртелгән лампалар тора.

Саба урманчылыгының агач эшкәртү предприятиеләрендә агач калдыкларының шактый күләмнәре: пычкы чүбе,йомычка һ.б. барлыкка килә. Агач калдыкларының шактый өлеше икенчел чимал буларак кулланыла яки халыкка сатыла.

Район территориясендә 2 каты көнкүреш калдыклары полигоны (1се Байлар Сабасы ш.т.б.дә, 1се Шәмәрдән авылында) бар, анда предприятие һәм оешма калдыклары, шулай ук районның торак секторы калдыклары кабул ителә.

Бүгенге көндә районның торак пунктларын чистартуның генераль схемасы эшләнгән, әмма контейнер мәйданчыклары җитмәү сизелә.

6. Җир ресурсларының торышы.

Саба районының гомуми мәйданы - 109 773,98 га. Төбәк территориясендә Байлар Сабасы ш.т.п., 2 эре торак пункт (Шәмәрдән авылы һәм Лесхоз бистәсе), Саба районында урнашкан башка 64 торак пункт бар .

Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең һәм фермер хуҗалыкларының төп юнәлешләре - ит-сөт, ашлык-терлекчелек, яшелчәчелек. Арыш, сабан бодае, бәрәңге- иң мөһим культуралардан санала.

Туфраклар агач-көлсу, урман-дала, кара туфрак, сазлыклар, урманнар белән тәкъдим ителгән.

## 2. Программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Әлеге Программаның максаты экологик иминлек өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәте формалаштыру, шулай ук Саба районының табигый мохитен торгызуга, саклауга һәм яхшыртуга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру.

Куелган максатларга ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителергә мөмкин:

- әйләнә-тирә мохит мониторингын һәм оештыру-оператив идарә итү системасын камилләштерү;
- әлеге Программага кертелгән чараларны этаплап гамәлгә ашыруны тәэмин итү, акчаларны үз вакытында һәм максатчан финанслау, алардан файдалану;
- халыкның барлык катламнары арасында гомуми экологик белем бирү сәясәте үткәрү.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа проектында түбәндәге финанслау чыганаклары каралган: РФ бюджеты; республика бюджеты, җирле бюджет, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары, башка чыганаклар.

Саба районында урнашкан икътисадый вазгыятьне исәпкә алып, Программа чараларын үтәүгә бүлеп бирелә торган чараларны вакыт-вакыт индексацияләүне күздә тотарга кирәк (1 нче кушымта).

Район бюджеты һәм башка финанслау чыганаклары хисабына каралган табигатьне саклау объектлары төзелешенә капитал салулар күләме һәм Саба районының әйләнә-тирә мохитен савыктыру чараларын үтәүгә бәйле башка чыгымнар ел саен аларны тиешле елга кабул иткәндә төгәлләштерелергә тиеш.

Программа иң өстенлекле юнәлешләр буенча районның экологик торышын исәпкә алып формалаштырылды.

## 4. Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Программаны эшләү икътисадый реформаларны дәвам итүнең кирәкле шарты булып тора.

Планлаштырылган чараларны гамәлгә ашыру район территориясендә пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны (ташлауларны) стабильләштерергә һәм

этаплап киметә башларга: социаль-икътисадый өлкәдәге кризис хәлен бетерү һәм сәнәгать производстволарында экология базасын булдыру буенча беренче чираттагы (кичектергесез) бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Аерым алганда, атмосфера һавасына чыгарыла торган зарарлы матдәләрнең санын һәм күләмен 20-25%ка киметергә, су объектларына зарарлы матдәләр керүне 15-20%какиметергә, халыкны сыйфатлы эчә торган сулар белән ышанычлы тәэмин итү проблемасын хәл итәргә, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерүне һәм күмүне тәртипкә салырга, халыкның экологик белемлелеген арттырырга, әйләнә-тирә табигать мохитен мониторинглауның нәтиҗәле системасын булдырырга.

Районда экологик вәзгыятьне савыктыру эше әлеге Программа кысалары белән генә чикләнми. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Саба муниципаль районы Советының билгеләнгән гамәлләре белән бер үк вакытта район предприятиеләрендә табигатьтән нәтиҗәле файдалану проблемаларын хәл итүдә комплекслы якын килү принципларын үстерергә, шулай ук халыкның табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлеге нормаларына туры китереп, районның социаль инфраструктурасын үстерү тәкъдим ителә.

2021-2025 елларга Саба муниципаль
районының экологик куркынычсызлыгын
тәэмин итү муниципаль программасына
1 кушымта

# 1 ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА

## “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу”

### 1 Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| 1 Ярдәмче программа исеме | “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу” ярдәмче программасы (алга таба -1 Ярдәмче программа ) |
| 1 Ярдәмче программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 1 Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы икътисадының экологик нәтиҗәлелеген арттыру нигезендә әйләнә-тирә мохиткә гомуми антропоген йөкләнешне киметү |
| 1 Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының әйләнә-тирә мохите торышын күзәтүнең территориаль системасын булдыру.<br>2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының атмосфера һавасын саклау.<br>3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җир ресурсларын саклау.<br>4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү.<br>5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының экологик белем дәрәҗәсен арттыру, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү |
| 1 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2021-2025 еллар |
| 1 Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре-1 | 2021-2026 елларда 1 Ярдәмче программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 9 035,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда - 1 807,000 мең сум;<br>2022 елда - 1 807,000 мең сум;<br>2023 елда - 1 807,000 мең сум;<br>2024 елда - 1 807,000 мең сум;<br>2025 елда - 1 807,000 мең сум.<br>1 ярдәмче Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

| | |
|---|---|
| 1 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре | 1 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру:<br>- җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен арттырырга;<br>- туфрак сыйфатының эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән региональ нормативлары санын арттырырга;<br>- табигатьне саклау, экология-агарту чараларында катнашучы халыкның гомуми саныннан халык өлешен арттырырга;<br>- чистарту корылмалары белән җиһазландырылган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бюджет учреждениеләре санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк. |

## 1. 1 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аны үстерү фаразы

Югары антропоген йөкләнеш атмосфера һавасының, җир өсте һәм җир асты суларының, туфракның зарарлы химик матдәләр белән пычрануына бәйле.

Хәл автомобиль транспорты паркының көчле үсеше белән катлаулана, бу исә азот диоксидының һәм атмосферадагы углерод оксидының концентрациясе артуга китерә.

Җирләрнең дәүләт мониторингы нәтиҗәләрен һәм әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтүнең башка системаларын анализлау җирләрнең торышы начарлану тенденциясе саклануын күрсәтә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирләренең гомуми мәйданы 109 773,98 гектар тәшкил итә.

Хуҗалык эшчәнлеге бозылган җирләрнең мәйданнары артуга, туфракның уңдырышлылыгы һәм продуктивлыгы югалуга, эрозия процессларының актив үсешенә, туфракның сәнәгатьтән чыккан агулы матдәләр белән пычрануына китерә.

Туфракның пычрануы аеруча экологик проблема булып тора. Хәзерге вакытта һава һәм климат турындагы белемнәр кеше яшәешенең күп кенә аспектлары өчен мөһим булып тора. Әйләнә-тирә табигать мохите торышының начараюы халыкның тормыш дәрәҗәсенә йогынты ясый, районнарның икътисадый һәм социаль үсеш мөмкинлекләрен чикли, инвестиция климатының начараюын һәм икътисадның конкурентлык сәләтен киметә.

Экология өлкәсендә килеп туган вәзгыять, шулай ук экологик вәзгыяткә өстәмә йөкләнеш булган сәнәгать потенциалы үсеше аркасында производстволарны алга таба киңәйтү, һичшиксез, комплекслы якын килү һәм экология өлкәсендәге проблемаларны программа методлары белән хәл итүне таләп итә.

Хәзерге вакытта экология юнәлешендә массакүләм чаралар үткәрүгә зур игътибар бирелә, чөнки алар белем дәрәҗәсен күтәрү мөмкинлеген генә түгел, бәлки районның табигый һәм тарихи-мәдәни мирасын өйрәнүгә яшүсмерләрне җәлеп итәргә мөмкинлек бирә, табигатькә һәм мәдәни кыйммәтләргә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләүгә, үз ягының табигатен, тарихын һәм традицияләрен өйрәнү нигезендә гражданлык җаваплылыгын һәм экологик культураны үстерүгә ярдәм итә.

Экологик-белем бирү һәм агарту эшчәнлеген гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына өзлексез экологик белем һәм тәрбия бирү системасын камилләштерергә ярдәм итәчәк, эколог җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсен арттыруны тәэмин итәчәк, шулай ук әйләнә-тирә мохит сыйфатын тәэмин итү өлкәсендә квалификацияле эшче кадрлар әзерләүнең икътисадый функциясен гамәлгә ашыра.

## 2. 1 Ярдәмче программаның төп максатлары һәм бурычлары, гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

1 Ярдәмче программаның максаты - икътисадның экологик нәтиҗәлелеген күтәрү нигезендә әйләнә-тирә мохиткә гомуми антропоген йөкләнешне киметү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны үтәргә кирәк:

әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтүнең территориаль системасын төзү;

атмосфера һавасын саклау;

җир ресурсларын саклау;

территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү;

экологик белем дәрәҗәсен күтәрү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә мәгълүмати яктан тәэмин итү.

“Атмосфера һавасын саклау” бурычы кысаларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгарып ташлауларны киметүне тәэмин итү буенча чаралар комплексы каралган.

“Җир ресурсларын саклау” бурычы кысаларында туфракның төп типларында төрле органик һәм органик булмаган пычраткыч матдәләр тоту нормативларын эшләү күздә тотыла.

“Территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү” бурычын гамәлгә ашыру кысаларында торак пунктларны яшелләндерү, парклар һәм скверлар төзү эшләрен башкару күздә тотыла.

“Экологик белем бирү дәрәҗәсен арттыру, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә мәгълүмати яктан тәэмин итү” бурычын гамәлгә ашыру кысаларында :

әйләнә-тирә мохитне саклау турында мәгълүмат бирү

экологик куркынычтан гомумроссия саклану көннәре чараларын оештыру һәм уздыру;

“Кеше һәм табигать” һәм “ЭКОлидер” конкурсларын оештыру һәм уздыру;

“Чиста караш” социаль экология рекламасы конкурсын оештыру һәм уздыру;

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен өзлексез экологик белем бирү системасын үстерү һәм халыкны тәрбияләү мәсьәләләре буенча сюжетлар һәм мәкаләләр әзерләү.

1 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары - 2021-2025 еллар.

## 3. 1 Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

2021-2025 елларда 1 Ярдәмче программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 9 035,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2021 елда - 1 807,000 мең сум;

2022 елда - 1 807,000 мең сум;

2023 елда - 1 807,000 мең сум;

2024 елда - 1 807,000 мең сум;

2025 елда - 1 807,000 мең сум.

1 ярдәмче Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

2021-2025 елларга Саба муниципаль
районының экологик куркынычсызлыгын
тәэмин итү муниципаль программасына
2 кушымта

# 2 ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА

**“2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә идарә”**

**2 Ярдәмче программа паспорты**

| | |
|---|---|
| 2 Ярдәмче программаның исеме | “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә идарә” 2 Ярдәмче программасы (алга таба - 2 Ярдәмче программа) |
| 2 Ярдәмче программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2 Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы әйләнә-тирә мохитенең пычрану дәрәҗәсен киметү |
| 2 Ярдәмче программаның бурычлары | Биологик үләксәләрне җыю, туплау, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру буенча инфраструктураны үстерү |
| 2 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2021-2025 еллар |
| 2 Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2021-2025 елларда 2 Ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 0,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда - 0,000 мең сум;<br>2022 елда - 0,000 мең сум;<br>2023 елда - 0,000 мең сум;<br>2024 елда - 0,000 мең сум;<br>2025 елда - 0,000 мең сум.<br>2 ярдәмче Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

## 1. 2 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аны үстерү фаразы

Калдыкларны туплау, куллану, зарарсызландыру, саклау һәм күмү белән бәйле критик вәзгыять бу проблеманы экологик проблемалар арасында беренче урынга чыгарды. Ул халыкның һәм киләчәк буыннарның сәламәтлегенә реаль куркыныч тудыра, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы

территориясендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү проблемасы экологик вәзгыятьне тотрыкландыру һәм яхшырту һәм районның ресурс потенциалын нәтиҗәле файдалану өчен иң мөһим проблемаларның берсе булып тора.

## 2. 2 Ярдәмче программаның төп максатлары һәм бурычлары, гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

2 Ярдәмче программаның төп максаты - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату дәрәҗәсен киметү. Бу максатка ирешү өчен Саба муниципаль районы территориясеннән биологик калдыкларны җыюны, саклауны һәм утильләштерүне оештыру кирәк. Хайваннарның үле гәүдәләрен җыю, транспортлау һәм зарарсызландыру тәртибе «Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юкка чыгару буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре» дип билгеләнгән, алар Россия Федерациясенең баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан 1995 елның 4 декабрендә расланды. Биологик калдыкларны җыю район хуҗалык субъектларыннан, халкыннан яисә ветеринария хезмәтеннән заявка кергән вакыттан алып 2 сәгать эчендә тәүлек буе башкарылырга тиеш. Биологик калдыкларны җыюны оештыру Россия Федерациясенең баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан 1995 елның 4 декабрендәге 13-7-2/469 номерлы раслаган биологик калдыкларны утильләштерү һәм юкка чыгару буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

2 Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары - 2021-2025 еллар.

## 3. 2 Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

2021-2025 елларда 2 Ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 0,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2021 елда - 0,000 мең сум;
2022 елда - 0,000 мең сум;
2023 елда - 0,000 мең сум;
2024 елда - 0,000 мең сум;
2025 елда - 0,000 мең сум.

2 ярдәмче Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының экологик
куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль
программасының 1 ярдәмче программасына
1 кушымта

## "2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу" 1 Ярдәмче программасы чаралары

| № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум. | | | | | Финанслау чыганагы | Көтелә торган нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | | |
| **1. Оештыру эшләре** | | | | | | | | | |
| 1.1. | Табигатьне саклау эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре буенча муниципаль районның норматив актларын эшләү | Башкарма комитет | Кирәк булганда | | | | | | |
| 1.2. | Муниципаль районда табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек комиссиясе эшен оештыру | Башкарма комитет | * | * | * | * | * | | |
| **2. Атмосфера һавасын саклау буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| **2.1.Автотранспорттан чыккан зарарлы матдәләрне киметүгә юнәлдерелгән чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.1.1 | Автотранспортны газга күчерү | «Яшен» ҖЧҖ | Кирәк булганда | | | | | предприятиеләр акчалары | экологик хәлнең торышын яхшырту |
| **2.2.Стационар чыганаклардан ташлауларны киметүгә юнәлдерелгән чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | Ташлаулар чыганакларында ПДВ нормативларының үтәлешен тикшереп тору һәм котлоагрегатларда CO, Nox чыгуны кимeтә торган яну режимнарын кертү, шул исәптән: | Саба районы предприятиеләре | | | | | | предприятиеләр акчалары | Атмосфераның җир асты катламында пычраткыч матдәләр концентрацияләрен кыскарту |
| 2.2.1.1 | Байлар Сабасы ш. т. б. Закиров ур., 44 адресы буенча урнашкан котельный | Саба ТКХ КТП | | | | | | | |
| 2.2.1. | Байлар Сабасы ш.т.б.дәге "Мунча" котельные | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | | | | | | | | |
| 2.2.1.3 | Байлар Сабасы ш.т.б.дәге "Квартал" котельные | | | | | | | | |
| 2.2.1.4 | Байлар Сабасы ш.т.б.дәге "Үзәк район хастаханәсе" котельные | | | | | | | | |
| 2.2.1.5 | Шәмәрдән авылындагы "Үзәк" котельные | Шәмәрдән ТКХ КТП | | | | | | | |
| | **2 бүлек буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **3. Су ресурсларын саклау буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| **3.1.Су ресурсларын саклау өлкәсендә гомуми чаралар** | | | | | | | | | |
| 3.1.1 | Гидротехник корылмалар реконструкциясе, шул исәптән | | | | | | | ТР бюджеты | |
| 3.1.1.1 | Урта Нырты торак пункты | Авыл җирлеге | | | | | | | |
| 3.1.1.2 | Явлаштау торак пункты | Авыл җирлеге | | | | | | | |
| 3.1.1.3 | Сәрдә торак пункты | Авыл җирлеге | | | | | | | |
| 3.1.2 | Агып төшүче суларның лаборатория контроле, шул исәптән | ТКХ КТП | | | | | | предприятиеләр акчалары | Агып төшүче суларның стандарт булмаган анализларын 0,1 %ка кадәр киметү |
| 3.1.2.1 | Саба ТКХ КТП | | | | | | | | |
| 3.1.2.2 | Шәмәрдән ТКХ КТП | | | | | | | | |
| 3.1.3 | Байлар Сабасы ш.т.б.дәгы Сабинка яр буе линиясе | Башкарма комитет | | | | | | ТР бюджеты | |
| 3.1.4 | Мамалай авылы янындагы О. Мишә елгасы буенда су юлын турайту эшләре | Башкарма комитет | | | | | | ТР бюджеты | |
| 3.1.5 | Т.Утар авылы янындагы елгада су юлын турайту эшләре | Башкарма комитет | | | | | | ТР бюджеты | |
| | **3.1 бүлеге буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **3.2.Чистарту һәм су җыю корылмаларын реконструкцияләү һәм төзү чаралары** | | | | | | | | | |
| 3.2.1 | Гамәлдә булмаган скважиналарны, шул исәптән торак пунктларда да тампонажлау: | Авыл җирлеге | | | | | | ТР бюджеты | Җир асты суларының пычрануын киметү |
| 3.2.1.1 | Түбән Шытсу авылы | | | | | | | | |
| 3.2.1.2 | Завод-Нырты авылы | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2.1.3 | Keче Шыңар авылы | | | | | | | | |
| 3.2.1.4 | Калатау бистәсе | | | | | | | | |
| 3.2.1.5 | Мамалай авылы | | | | | | | | |
| 3.2.1.6 | Теneки авылы | | | | | | | | |
| 3.2.1.7 | Югары Шытсу авылы - 2 данә | | | | | | | | |
| 3.2.1.8 | Елыш авылы | | | | | | | | |
| 3.2.1.9 | Чәбия Чүрчи | | | | | | | | |
| 3.2.1.10 | Б.Сабасы ш.т.б. | | | | | | | | |
| 3.2.2 | Санитария саклау зоналарын төзекләндерү, шул исәптән | | | | | | | | |
| 3.2.2.1 | Тимершык авылы № 13 | | | | | | | | |
| 3.2.2.2 | Сабай авылы № 27 | | | | | | | | |
| 3.2.2.3 | Эзмә авылы № 8 | | | | | | | | |
| 3.2.2.4 | Керәнле авылы № 10 | | | | | | | | |
| 3.2.2.5 | Югары Шытсу № 25 | | | | | | | | |
| 3.2.2.6 | Мамалай авылы № 26 | Авыл җирлеге | | | | | | ТР бюджеты | Су белән тәэмин итү объектларының иминлеген тәэмин итү |
| 3.2.2.7 | Сатыш авылы № 17 | | | | | | | | |
| 3.2.2.8 | Йосыф-Алан авылы № 16 | | | | | | | | |
| 3.2.2.9 | Туктар авылы № 19 | | | | | | | | |
| 3.2.2.10 | Урта Нырты № 20 | | | | | | | | |
| 3.2.2.11 | Арташ авылы № 21 | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2.2.12 | К. Кибәче авылы № 24 | | | | | | | | |
| 3.2.2.13 | Югары Симет авылы № 11 | | | | | | | | |
| 3.2.2.14 | Б.Сабы ш.т.б. | | | | | | | | |
| 3.2.3 | Социаль-мәдәни объектларда ОС төзелеше | | | | | | | жирле бюджет | |
| 3.2.4 | «Шәмәрдән ит комбинаты» ААЖендә ОС төзү | ААЖ "Шәмәрдән ит комбинаты" | | | | | | предприятиеләр акчалары | Ташлаулар елга 18000 мең тоннага төште |
| 3.2.5 | «Вамин» ҖЧҖенең «Саба май заводы» ААҖендә ОС төзү | «Саба май заводы» ААҖ | | | | | | предприятиеләр акчалары | Ташлаулар елга 22000 мең тоннага төште |
| | **3.2 бүлеге буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **3.3.Канализация һәм суүткәргеч челтәрләрен реконструкцияләү һәм төзү чаралары** | | | | | | | | | |
| 3.3.1 | Байлар Сабасы бистәсенең Көнбатыш өлешендә канализация челтәрләре төзү | Башкарма комитет | | | | | | РФ, ТР бюджеты | бистә халкын үзәк канализация белән тәэмин итүне 40%ка кадәр арттыру |
| 3.3.2 | Байлар Сабасы ш.т.п. Көнбатыш өлешендә торак йортларны су белән тәэмин итү | Башкарма комитет | | | | | | РФ, ТР бюджеты | халыкны үзәк су белән тәэмин итүне 85 %ка кадәр арттыру |
| | **3 бүлек буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **4. Җир ресурсларын саклау буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| 4.1 | Бозылган җирләрне рекультивацияләү, шул исәптән: | | | | | | | | |
| 4.1.1 | 9,6 га мәйданда кыргый карьерларны рекультивацияләү, 20 данә. | Авыл җирлеге | | | | | | РФ, ТР бюджеты | |
| | | Авыл җирлеге | | | | | | җирле бюджет | |
| 4.1.2 | 1,9 га мәйданда эчке файдаланудагы карьерларны реконструкцияләү, 12 данә. | Район предприятиеләре | | | | | | предприятиеләр акчалары | |
| 4.2 | Саклагыч урман утыртмаларын булдыру буенча эшләрне башкаруны тәэмин итү, шул исәптән | Саба урман хуҗалыгы | | | | | | РФ бюджеты, ТР, предприятие акчалары | Гомуми файдаланудагы яшел |
| 4.2.1 | эрозиягә каршы 5 га | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.2.2 | юл буе утыртмалары белән 5 га | | | | | | | | утыртмалар белән 40 %ка кадәр тәэмин итү |
| 4.2.3 | кыр яклаучы утыртмалар белән 5 га | | | | | | | | |
| | **4 бүлек буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **5. Биологик ресурсларны саклау буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| 5.1 | Байлар Сабасы бистәсендә Әфганчылар паркын төзү | | | | | | | ТР бюджеты | Гомуми файдаланудагы яшел утыртмалар белән 40 %ка кадәр тәэмин итү |
| 5.2 | Сәнәгать предприятиеләре һәм учреждениеләренә, кече һәм урта бизнес объектларына якын территорияләрне төзекләндерү - 2,4 гектар мәйданлы 12 территория | Район предприятиеләре | | | | | | предприятиеләр акчалары | |
| 5.3 | Карт агачларны кисү һәм яшел үсентеләр утырту | ТКХ КТП | | | | | | предприятиеләр акчалары | |
| 5.4 | Халыкның яшел фондын инвестицияләү | Авыл җирлеге | | | | | | Агымдагы финанслау | |
| | **5 бүлек буенча барлыгы** | | | | | | | | |
| **6. Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналардагы чаралар** | | | | | | | | | |
| 6.1 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичәнбаш авылы янында урнашкан себер түләмәсе үләт базасының санитар-яклау зонасын кыскарту чарасы | Башкарма комитет | 1 807, 000 | 1 807, 000 | 1 807, 000 | 1 807, 000 | 1 807, 000 | җирле бюджет | |
| | **6 бүлек буенча барлыгы** | | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | | |
| **7. Экологик тәрбия һәм мәгариф** | | | | | | | | | |
| **7.1. Гаиләдә экологик тәрбия һәм белем алу** | | | | | | | | | |
| 7.1.1. | Муниципаль дәрәҗәдә гаилә экологик тәрбиясе тәҗрибәсен өйрәнү һәм аны нәшрият эшчәнлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары, клуб һәм башка эш формалары аша тарату | РОО, ОК | Ел саен | | | | | | |
| 7.1.2. | Балаларны гаиләдә экологик тәрбияләү турында белешмәләр банкын булдыру һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре хезмәткәрләре белән әлеге тәҗрибәне анализлау | РОО | Ел саен | | | | | | |
| 7.1.3. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре, китапханәләр, оешмалар каршында гаилә экология клубларын оештыру | РОО, ОК | Ел саен | | | | | | |
| 7.1.4. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең һәм башлангыч мәктәпләрнең планнары һәм программалары белән район планнарын һәм гаилә экология тәрбиясе | РОО | Ел саен | | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | программаларын килештерү | | | | |
| **7.2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә экологик тәрбия һәм белем бирү** | | | | | |
| 7.2.1. | Муниципаль дәрәҗәдә гаиләдә экологик тәрбия бирү тәҗрибәсен анализлау һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең планнарын мәктәпкәчә яшьтәге балаларга гаиләдә экологик тәрбия бирү юнәлешләре белән килештерү | РОО | Ел саен | | |
| 7.2.2. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында район планнары белән экологик белем бирү планнарын килештерү | РОО | Ел саен | | |
| 7.2.3. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик белем бирүнең яңа технологияләрен эшләү буенча районның мәктәпкәчә учреждениеләрендә база һәм эксперименталь мәйданчыклар булдыру | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.2.4. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрдәге экологик белем бирү тәҗрибәсе турында район белешмәләр базасын булдыру | РОО | Ел саен | | |
| 7.2.5. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә экологик-белем бирү киңлеген булдыру буенча методик тәкъдимнәр әзерләү һәм бастырып чыгару | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.2.6. | Районның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре базасында "Мастер-класста дәресләр" тәрбияче-экологлар өчен семинар | РОО | Ел саен | | |
| **7.3. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә экологик белем** | | | | | |
| 7.3.1. | Мәктәптә экологик белем бирү тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм анализлау һәм аны методик семинарлар һәм конференцияләр үткәргәндә экологик белем бирү системасын камилләштерү өчен куллану | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.2. | Төп мәктәптә өзлексез экологик практика юнәлешләрен һәм нәтиҗәләрен анализлау һәм укытуның алдагы һәм аннан соңгы этаплары белән ' практика планнарын һәм программаларын килештерү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.3. | Укучыларны бергәләп укыту рәвеше буларак район практик экология мәктәбен (хезмәтне һәм ял итүне оештыруның кышкы һәм җәйге сменасын) үткәрү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.4. | Барлык уку предметларының эчтәлеген экологияләштерү буенча укытучылар өчен район | РОО | Ел саен | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | семинарларын оештыру | | | | |
| 7.3.5. | 9 сыйныф укучыларын һөнәр буенча алдан әзерләү буенча эш | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.6. | Мәктәп укучылары белән дәресләрнең класстан тыш формаларын оештыру ("Яшь урманчы", "Яшь агроном", "Яшь эколог" һ.б.) | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.7. | 5-9 сыйныф укучылары өчен бердәм сезонлы экологик практика оештыру | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.8. | 5 - 9 сыйныфларда сезонлы экологик практиканы оештыру буенча укытучылар өчен район семинарлары үткәрү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.9. | Төп мәктәптә табигый-фәнни цикл предметлары эчтәлеген экологияләштерү буенча укыту-методик киңәшләр, пособиеләр эшләү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.10. | Төп мәктәптә экологик белем бирү тәҗрибәсеннән район белешмәләр банкын төзү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.11. | Экологик белем бирү буенча укыту-методик ярдәмлекләрнең тәкъдим итү исемлеген төзү | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.12. | 5-9 нчы сыйныфларда экологик белем торышын мониторинглау | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.13. | Экологик мониторинг уздыру буенча база мәктәпләре челтәрен булдыру | РОО | Ел саен | | |
| 7.3.14. | 10 нчы сыйныфларда экология буенча сезонлы һәм җәйге кыр практикасын оештыру (укыту-тикшеренү экспедицияләре һәм экология лагерьлары) | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| **7.4.Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә экологик тәрбия** | | | | | |
| 7.4.1. | Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә экологик белем бирүне үстерүне перспективалы планлаштыру | РОО | Ел саен | | |
| 7.4.2. | Балалар көндез ял итә торган җәйге экологик мәктәпләр һәм лагерьлар оештыру | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.4.3. | Мәктәп укучыларының экология буенча тикшеренү эшләре нәтиҗәләре буенча район конкурслары һәм фәнни-гамәли семинарлар, конференцияләр үткәрү | РОО | Ел саен | | |
| 7.4.4. | Укучыларның экологик олимпиадаларын үткәрү | РОО | Ел саен | | |
| 7.4.5. | Яшь экологлар мәктәпләрен булдыру | РОО | Ел саен | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7.4.6. | Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре белән үзара бәйләнеш кысаларында мәктәпкәчә һәм мәктәптә сәнгать-эстетик, декоратив-гамәли, экологик-туган якны өйрәнү, этнографик һәм башка юнәлешләрне үстерү | РОО | Ел саен | | |
| 7.4.7. | "Экологик куркынычтан яклау көннәре" Бөтенроссия акциясенең "Иминлек мәктәбе" район балалар-яшүсмерләр иҗтимагый хәрәкәтендә , Идел буе фәнни-гамәли экологик конференциясе эшендә катнашу һәм башкалар | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.4.8. | Иҗтимагый экология акцияләрен оештыруда һәм уздыруда өстәмә белем бирү учреждениеләренең катнашуы | РОО | Ел саен | | |
| 7.4.9. | Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре базасында экология-белем бирү массакүләм эшенең смотрларын, күргәзмәләрен, конкурсларын һәм башка рәвешләрен оештыру | РОО, ОК | Ел саен | | |
| **7.5. Экологик иминлекне тәэмин итү эше** | | | | | |
| 7.5.1. | Экология куркынычсызлыгы буенча координация советын төзү | Башкарма комитет | Ел саен | | |
| 7.5.2. | Экологик иминлек буенча уку программалары, дәреслекләр, методик әдәбият белән тәэмин итү | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.5.3. | Биология, химия, экология, география укытучыларының методик берләшмәсе эшен координацияләү һәм системалаштыру | РОО | Ел саен | | |
| **7.6. Белгечләрне яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү** | | | | | |
| 7.6.1. | Мәгариф системасы җитәкчеләрен һәм белгечләрен яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү программасында катнашу | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.6.2. | Укучыларның һәм педагогик хезмәткәрләрнең экологик белем бирү программаларына һәм тикшеренү эшләренә ярдәм итү өчен шартлар тудыру | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.6.3. | Белем бирү учреждениеләренең күмәк шартнамәләренә әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлык өлкәсендә җитәкчеләр һәм белгечләр әзерләү бүлеген кертү | РОО | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| **7.7. Экологик агарту** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7.7.1. | Китапханә челтәре аша "Туган якның мәдәни һәм табигый мирасы" программасын гамәлгә ашыру | РОО, ОК | Ел саен | | |
| 7.7.2. | Мәгариф учреждениеләренең мәдәни-ландшафт комплексын, экологик белем һәм тәрбия бирүне оештыру буенча модельле объект буларак архитектура-этнография музеен үстерү | РОО, ОК | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.7.3. | Үсеп килүче буын белән экология-белем бирү эшчәнлеген үткәрү өчен экология ягыннан якын килү нигезендә табигать бүлекләре экспозицияләрен төзүдә районның туган якны өйрәнү музейларына ярдәм итү | РОО, ОК | Ел саен | | |
| 7.7.4. | Халыкны экологик агарту буенча мәктәп китапханәләре эшчәнлегенең район смотр-конкурсларын үткәрү | РОО, ОК | Ел саен | | |
| 7.7.5. | Экологик белем бирү, тәрбия һәм агарту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы аерым иҗтимагый төркемнәрнең һәм хәрәкәтләрнең иҗади инициативаларына ярдәм итү | РОО, ОК | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.7.6. | “Экологик куркынычтан яклау көннәре”, табигатьне саклау айлыгы, “Мәктәп ишегаллары маршы”; “Балалар мәйданчыклары маршы”; “Безнең мирас” (районның табигый һәм тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау); “Экологик чиста ишегалды”; “Яшел урам” һәм башка чаралар үткәрү. | РОО, ОК | Ел саен | | |
| 7.7.7. | Музейлар базасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, мәктәп укучыларына һәм һөнәри лицейга экологик белем бирү эшен оештыру | РОО, ОК | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.7.8. | "Яшә җир" кулланучыларын экологик агарту буенча максатчан китапханә программасын гамәлгә ашыру | РОО, ОК | Ел саен | | |
| 7.7.10. | Төзекләндерү буенча «Иң яшел китапханә», «Иң яшел мәдәният йорты», « Иң яшел сәнгать мәктәбе», «Иң яшел музей» исеменә «Һәр торак пунктка - үрнәк мәдәният учреждениеләре» дигән район смотр-конкурсын үткәрү | РОО, ОК | Ел саен | Агымдагы финанслау | |
| 7.7.11. | Яшь фоторәссамнарның “Урманнарның ягымлы шаулавы мәңге күңелләрне сөендерсен”дигән район бәйгесен үткәрү | РОО, ОК | Ел саен | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.7.12. | Үсеп килүче буын белән экология-белем бирү эшчәнлеге базасында экология-белем бирү эшчәнлеге алып бару өчен экологик алым нигезендә табигать бүлекләре экспозициясен төзүдә районның туган якны өйрәнү музейларына ярдәм итү | РОО, ОК | Ел саен | | | | | Агымдагы финанслау | |
| **7.8.Иҗтимагый хәрәкәтләр һәм экологик белем бирү** | | | | | | | | | |
| 7.8.1. | Экологик белем бирү һәм тәрбия бирү нәтиҗәләре буенча конкурслар, күргәзмәләр оештыруда һәм уздыруда катнашу | РОО | Ел саен | | | | | Агымдагы финанслау | |
| 7.8.2. | "Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә иң яхшы экологик үсеш мохите" район конкурсы оештыру | РОО | Ел саен | | | | | Агымдагы финанслау | |
| 7.8.3. | "Экологик яктан төзекләндерелгән мәктәп ишегалды" проектлары конкурсы | РОО | Ел саен | | | | | Агымдагы финанслау | |
| 7.8.4. | Экологик белем бирү проектларын гамәлгә ашыру буенча экодайджестаның даими чыгарылышы | РОО | Ел саен | | | | | | |
| 7.8.5. | Экологик белем бирүнең торышы турында еллык аналитик белешмә әзерләү | РОО | Ел саен | | | | | | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | **1 807, 000** | | |

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының экологик
куркынычсызлыгын тәэмин итү муниципаль
программасының 2 ярдәмче программасына
1 кушымта

| № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Финанслау күләме, мең сум. | | | | | Финанслау чыганагы | Көтелә торган нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | | |
| **1. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге чаралар** | | | | | | | | | |
| **1.1** | Биологик үләксәләрне туплауны,саклауны, алып китүне оештыру | Башкарма комитет | 0,000 | 0,000 | 0,000 | 0,000 | 0,000 | ТР бюджеты | Экологик иминлекне яхшырту |
| | **БАРЛЫГЫ:** | | **0,000** | **0,000** | **0,000** | **0,000** | **0,000** | | |